РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«15» мая 2026 г. г. Альметьевск № 45

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 253 номерлы «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы Нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 25 январендагы 71 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»гы 2024 елның 13 июлендәге 539 номерлы Указы, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2026 елның 31 мартындагы 02-08-01/45 номерлы протестын карап,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 253 номерлы «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы Нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 12 мартындагы 367 номерлы, 2020 елның 30 октябрендәге 12 номерлы, 2021 елның 11 мартындагы 36 номерлы, 2021 елның 16 декабрендәге 114 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 143 номерлы, 2023 елның 6 декабрендәге 266 номерлы, 2024 елның 13 ноябрендәге 322 номерлы, 2025 елның 7 мартындагы 343 номерлы, 2025 елның 28 ноябрендәге 14 номерлы, 2026 елның 27 мартындагы 40 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «Хезмәт (вазифаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия турындагы нигезләмә» 1 нче кушымтада:

1.1.1. 1 бүлекнең 1.3 пункты «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә җайга салу, коррупциягә каршы тору максатларында 273-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән (алга таба - хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләре);»;

1.1.2. 3 бүлектә «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга кагылышлы мәсьәләләрне комиссия тарафыннан карау тәртибе»:

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасы өстәргә:

«е) муниципаль хезмәткәргә хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә комачаулый торган аңа бәйле булмаган хәлләр барлыкка килү турында хәбәр итү.»;

3.2.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д», «е» пунктчаларында күрсәтелгән белдерүләрне карау нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органына муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче граждан белән хезмәттәшлек турында дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә, Федераль законның 273-ФЗ номерлы 12 статьясында таләп ителгәнчә.»;

3.2.5 пунктта «һәм әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «д» подпунктында,» сүзләрен «һәм әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «д», «е» подпунктларында,» сүзләренә алмаштырырга;

3.2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.2.1, 3.2.3, 3.2.4 пунктларында каралган мотивлаштырылган бәяләмәләр:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д», «е» пунктчаларында күрсәтелгән гаризаларда яисә хәбәрнамәләрдә бәян ителгән белешмәләр;

б) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан запрослар нигезендә алынган мәгълүматны;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д», «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең яисә башка карарның 3.9, 3.10.3, 3.10.4 һәм 3.11.1 пунктлары нигезендә карарның берсен кабул итү өчен тәкъдимнәр.»;

3.3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д», «е» пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамәләр, кагыйдә буларак, комиссиянең чираттагы (план) утырышында карала.»;

3.4 пунктта «әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасы белән» сүзләрен «әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б», «е» пунктчаларына алмаштырырга.»;

3.4.1 пунктының «а» подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) әгәр дә әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б», «е» пунктчалары белән каралган гаризада, хәбәрнамәдә муниципаль хезмәткәрнең яисә гражданның комиссия утырышларында шәхсән катнашуы турында күрсәтмә булмаса;»;

3.10 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3.10.4 пункты өстәргә:

«3.10.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәргә бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу белән аның тарафыннан хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкинлеге булмавы арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше барлыгын таныргa;

б) муниципаль хезмәткәргә бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу белән аның тарафыннан хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкинлеге булмавы арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын таныргa.»;

3.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча һәм моңа нигезләр булганда комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.7-3.10, 3.10.1-3.10.4 һәм 3.11.1 пунктларында каралганнан башка карар кабул итә ала. Мондый карар кабул итү нигезләре һәм мотивлары комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»на (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Туманова Г.П.).

Муниципаль район Башлыгы Г.М. Хәбутдинова